СОВЕТ
АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.22,
с. Азеево,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ АКЪЯР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Совет урамы, 22,
Акъяр авылы,423190

тел.: (8-84348) 3-71-31, факс: (8-84348) 3-71-61, Azeev.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Акъяр авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2022 елның 30 декабре №29-98

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның
өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Хисапланган көннән соң өч ел үткәч барлыкка килгән җирле салымнар суммалары өлешендә һәм федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә түләнмәгән бурыч җыюга өметсез дип таныргa.
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советы түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип таныргa:

2011 елның 13 нче октябре 12-34 нчы номерлы «Җирле салымнар һәм җыемнар буенча пенялар, штрафлар буенча бурычларны түләтүгә һәм исәптән төшерүгә өстәмә нигезләрне раслау турында» карар;

2021 елның 15 нче декабре 17-52 нче номерлы "Җирле салымнар һәм җыемнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча недоимкаларны һәм бурычларны түләтүгә һәм исәптән төшерүгә өметсез дип тану тәртибе турында» карар.

3. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http://novosheshminsk.tatarstan.ru.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Акъяр
авыл җирлеге башлыгы Д.С.Гайнуллин